**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

09 октября, 2023 ел Мәләкәс авылы № 19

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Җирекле авыл җирлеге Мәләкәс авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районынын «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2023 елның 22 октябренә 11:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылында Ветераннар,Көнчыгыш, Дуслык, Җирекле,Көнбатыш, Йолдыз, Я.П.Катков ,Чишмә, Божра урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Иске Җирекле авылы, Дуслык ур., 25А.й. (авыл клубы бинасы); янында билгеләргә.

2. 2023 елнын 22 октябренә 13:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылында Зәңгәрсу, Урман, Болын, Яшьлек, Магистраль, Тынычлык, Өмет, Халык, Парк, Басу, Бакча, Парк тыкрыгы, Дуслык тыкрыгы. урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Иске Җирекле авылы, Дуслык ур., 25А.й. (авыл клубы бинасы); янында билгеләргә.

3. 2023 елның 22 октябренә 15:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылында Бердәмлек, Кояшлы, Наратлык, Чәчәк, Узяк, Чаллы, И.Ш.Шакуров, Энтузиастлар, Гәрәбә урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Иске Җирекле авылы, Дуслык ур., 25А.й. (авыл клубы бинасы); янында билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (биер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен

киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юлларны ремонтлау;
- урамнары яктырту;
- территориясен төзекләндерү (тротуарны төзекләндерү);
- ял итүне оештыру һәм авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру (ноутбук сатып алу);
- чикләрендә су белән тәэмин итүне оештыру (реконструкция);
- территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру (ТАССРның 100 еллыгы паркында волейбол мәйданчыгын төзекләндерү);
- зиратны саклау өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Иске Җирекле авылы, Дуслык ур., 25А.й. (авыл клубы бинасы).

6. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев